УДК 001.83(100)

*А.Р. Москвина*

# МӘГАРИФ, ФӘН ҺӘМ МӘДӘНИЯТ ӨЛКӘЛӘРЕНДӘ ТАТАР-КАЗАКЪ МӨНӘСӘБӘТЛӘРЕНЕҢ ЯҢА ФОРМАЛАРЫ

*(ТР ФА Г. Ибраһимов исем. ТӘһСИ тәҗрибәсеннән)*

В статье рассматриваются вопросы международного сотрудничества в сфере науки и культуры на примере Республики Татарстан и Казахстана. В частности, анализируются связи Института языка, литературы и искусства им. Г. Ибрагимова АН РТ с научными учреждениями Казахстана, раскрывается потенциал различных форматов сотрудничества.

**Ключевые слова:** международное сотрудничество в сфере науки и культуры, научные связи, международные связи Института языка, литературы и искусства им. Г. Ибрагимова АН РТ.

Яңа меңьеллык чигендә, глобальләштерү дәверендә традицион сәнгати мәдәниятебез, тарих, телебез нигезен өйрәнү милли сыйфатларыбызны, рухи кыйммәтләрне саклап калуның төп шарты булып санала. Милли мәдәни һәм фәнни өлкәләр аерымланган хәлдә үсешкә ирешә алмый. Татарстан өчен соңгы дистә елларда бу юнәлештәге эш дәүләтнең актив ярдәме белән алып барыла.

Республикада милли филология, әдәбият белеме һәм сәнгать белеме өлкәләрендәге фәнни тикшеренүләр һәм татар халкының рухи кыйммәтләрен саклау, шул исәптән башка халыклар, аеруча төрки кардәшләр белән мәдәни фәнни һәм сәнгати багланышлар алып бару миссиясен үтәүдә ТӘҺСИ әйдәүче фәнни оешма булып тора. Хәзерге вакытта Татарстанда гына түгел, Россиядә, якын һәм ерак чит илләрдә яшәүче татарларның матди һәм рухи мәдәниятен тикшереп өйрәнү активлаша бара, үзара фәнни һәм мәдәни элемтәләр торгызыла, күп милләтле пространство шартларында тел, мәдәният, сәнгать үсеше закончалыклары һәм үзенчәлекләре ачыклана. Татар телен, әдәбиятын һәм сәнгатен төрки халыкларның рухи мирасы яссылыгында өйрәнү милли (татар) фән өчен уңышлы нәтиҗәләр яуларга мөмкинлек бирә.

ТР ФА Г. Ибраһимов исем. Тел, әдәбият һәм сәнгать институты бу юнәлештә үз эшен Россиянең Башкортстан, Мари Эл, Чувашстан, Тыва Республикаларындагы, Түбән Новгород, Әстерхан, Омск, Төмән һ.б. өлкәләрендәге һәм Пермь краендагы, Азәрбайҗан, Үзбәкстан, Казакъстанның татарлар күпләп яши торган төбәкләрендәге, Иран, Төркмәнстан, Төркиядәге фәнни үзәкләр белән тыгыз элемтәдә алып бара. Киң спектрдагы уртак проектларны тормышка ашыруга яшь галимнәр дә

тартыла. Әлеге язма кысаларында Г. Ибраһимов исем. ТӘһСИ белән Казакстан арасында барган фәнни диалогка киңрәк тукталып узу урынлы булыр.

Мәгариф системасы буенча Алматы шәһәрендәге шушы өлкә белән шөгыльләнүче М.О. Ауэзов исемендәге әдәбият һә сәнгать институты белән элемтәләр киңәя. 2016 елның май аенда аннан өч магистрант Казанга килеп «Әдәбият белеме» буенча стажировка уздылар (аның кысаларында фәнни архивларны тикшереп өйрәнү эшләре, әлеге проблемалар белән шөгыльләнүче яшь галимнәр белән танышу каралган иде).

Фәнни элемтәләр төрле юнәлешләр буенча Казанда һәм Казакъстанның фәнни үзәкләрендә оештырыла торган конференцияләр ярдәмендә ныгытыла (әлбәттә, аларның һәркайсында яшь белгечләр дә катнаша). Мәсәлән, ТР ФА Г. Ибраһимов исем. Тел, әдәбият һәм сәнгать институты оештырган «Фольклор системасында милли һәм гомумкешелек кыйммәтләре» дигән халыкара фәнни-гамәли конференциядә (2014 ел, апрель) Б.У. Азибаева (М.О. Ауэзов исем. Әдәбият һәм сәнгать институты) Ж.А. Аймухамбетова, К.К. Сарекенова (Л.Н. Гумилев исем. Евразия милли университеты), Р. Абилхәмит кызы (Казакъстан Республикасының С. Сәйфуллин исем. агротехник университеты) катнаштылар. А.К. Ниязов (Казакъстан Республикасы милли сәнгать академиясе) педагог-мәгърифәтче, рәссам Ш.А. Таһировның тууына 150 ел тулуга, ә Р.И. Каргабекова (М.О. Ауэзов исем. Әдәбият һәм сәнгать институты) белән С.Ж. Кобжанова (Казакъстан Республикасының А. Кастеев исем. дәүләт сәнгать музее) П.М. Дульскийның тууына 135 ел тулуга багышланган халыкара фәнни-гамәли конференциягә килделәр.

2009 елда Казанда уздырылган «Төрки дөньяда киез сәнгате: үткәне һәм бүгенгесе» халыкара симпозиумында киез басу осталары династиясеннән Беспековлар гаиләсе катнашты.

Җаекта (Уральскида) М. Утемисов исем. Көнбатыш Казакъстан дәүләт университеты һәм шул ук исемдәге музей базасында күренекле татар шагыйре Г. Тукайның тормыш юлы һәм иҗатына багышлап уздырылган конференцияләргә ТӘһСИ галимнәре дә чакырылган иде. 2016 елның апрелендә Алматыда «XX гасыр – XXI гасыр башында сәнгать белеме мәсьәләре» дигән халыкара фәнни-гамәли конференциядә безнең Институтның яшь галимнәре (М. Газизова белән Л. Шкляева) катнашты.

Мәдәниятара диалогны үстерүдә мәдәни өлкәдәге элемтәләрне, мәдәни вакыйгалар хакында мәгълүмат алышуны киңәйтү зур әһәмияткә ия. ТР ФА Г. Ибраһимов исем. Тел, әдәбият һәм сәнгать институты Казакъстан Республикасының Алматыдагы Т.К. Жургенов исем. Сәнгать академиясе, М.О. Ауэзов музей-йорты һәм Семей шәһәрендәге Невзоровлар гаиләсе исемен йөрткән Сәнгать музее белән хезмәттәшлек итә. «Татарстан һәм Казакъстан рәссамнары», «Төрки театрлар рәссамнары» дигән

алмаш күргәзмәләр оештыру буенча эш алып барыла.

Фәнни басмалар әзерләү өлкәсендә ТР ФА Г. Ибраһимов исем. ТӘһСИ белән Казакъстан Республикасы Мәгариф һәм фән министрлыгының Фән комитеты каршындагы М. Ауэзов исем. Әдәбият һәм сәнгать итституты арасында хезмәттәшлек итү буенча килешү төзелде. Аның кысаларында «Төрки тел театрлары фестиваль хәрәкәте» җыентыгы, «Казакъстан рәссамнарының тасвирый сәнгате үсешенә Татарстан рәссамнары йогынтысы» дигән очерклар сериясе бастырып чыгару планлаштырыла. Г. Тукайның тормыш юлын һәм иҗатын колачлаган персональ энциклопедиядә дә Казакъстан галимнәренең өлеше бар.

ТР ФА Г. Ибраһимов исем. ТӘҺСИ Казакъстанның А. Байтурсынов исем. Тел белеме институты белән хезмәттәшлек итә. 2014 елның май аенда безнең Институт галимнәре Алматыда булып, озак вакытлы фәнни хезмәттәшлек турында сөйләшеп кайтканнар иде. 2016 елның июнендә яшь галимнәребез, Татарстан Республикасыннан читтә тупланып гомер итүче татар халкының туган телен, тарихын һәм мәдәниятен өйрәнү максаты белән, Казакъстанның Семей шәһәрендә булып кайттылар.

ТӘҺСИның Язма һәм музыкаль мирас үзәге хезмәткәрләре белән Астана шәһәрендәге Халыкара төрки академия галимнәре тарафыннан ««XX гасыр башы төрки-татар вакытлы матбугатының электрон-мәгълүмати сайты»н булдыру», Г. Рәхим белән Г. Гобәйдуллинның «Татар әдәбияты тарихы»» басмасын текстологик әзерләп нәшер итү, «Аталар мирасы» программасы нигезендә Сәиф Сараи әсәрләрен, Корбангали Халидинең «Тәварихы хәмсәи шәркыйә» хезмәтен текстологик яктан басмага әзерләү буенча уртак проектлар тормышка ашырыла.

2016 елның апрелендә Э.Р. Каюмова М.О. Ауэзов исем. Әдәбият һәм сәнгать институтында «Хәзерге этапта Татарстанда музыка белеме: проблемалар һәм перспективалар» һәм «Республикада традицион мәдәниятне үстерү үзәге эшчәнлеге юнәлешләре һәм нәтиҗәләре турында» дигән темалар буенча чыгышлар ясады. Алар Казакъстан институты хезмәткәрләренә татарларда музыка белеме һәм фольклористиканың бүгенге торышы, өр-яңа әдәби һәм музыкаль язмалар белән якыннан танышырга мөмкинлек бирде, шулай ук төрки телле халыкларның рухи мәдәниятен чагыштырма планда өйрәнеп тикшеренүче Казакъстан галимнәре өчен бай материал булып хезмәт итәчәк.

Хәзерге вакытта Халыкара төрки академия белән берлектә «Аталар мирасы» күптомлыгын әзерләү проекты өстендә эш алып барыла.

2008 елдан ТР ФА Г. Ибраһимов исем. Тел, әдәбият һәм сәнгать институты күппрофильле фәнни-тикшеренү институтлары белән халыкара хезмәттәшлек өлкәсендәге традицияләрне дәвам итә. Бу юнәлештә мәгълүмати багланышларны киңәйтү

һәм фәнни эшчәнлектә үзара фәнни-методологик йогынтыны көчәйтү, лекция курсларын алып баруда автор-белгечләр алмашу, фәнни материаллар һәм тикшеренү нәтиҗәләре турындагы басма хезмәтләр белән танышып бару, фәнни эшләрне рецензияләүдә үзара хезмәттәшлекне җәелдерү, хезмәткәрләр өчен фәнни стажировкалар оештыру зур әһәмияткә ия. Югарыда саналган чаралар татар фәнен халыкара казанышлар үрнәгендә үстерергә ярдәм итәчәк. Яшь галимнәр белән уртак фәнни тикшеренүләрне дә ешрак уздырасы иде. Онлайн конференцияләр, фәнни-гамәли семинарлар, форумнар, тематик симпозиумнар, дистанцион белем бирү, архив базалары онлайнына үтеп керү, бергәләп күргәзмәләр, яшь белгечләр өчен стажировкалар оештыру да уңай нәҗитәләргә юл ачар иде.

***Москвина Альбина Ринат кызы,***
*ТР ФА Г. Ибраһимов исемендәге Тел, әдәбият*
*һәм сәнгать институтының тасвирый һәм декоратив-гамәли*
*сәнгать бүлеге фәнни хезмәткәре*